Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегенең
Шөгерчә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

21 ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022 елның 18 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта булган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге "2023 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Троицкий авыл җирлегенең Шөгерчә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым керту һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су башнясы территориясен киртәләү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 34 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 22 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 22 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегенең Шөгерчә авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Троицкий авыл җирлегенең Шөгерчә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым керту һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару: су башнясы территориясен киртәләү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләүгә ризамы?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Шөгерчә авылы, Үзәк урамы, 1 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Троицкий авыл җирлеге башлыгы Л.И. Горбунова